**СОВЕТ ТУБЫЛГЫТАУСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Ул.Молодежная, д.73,
с. Тубылгы тау,423181

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТУБЫЛГЫТАУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

Яшьләр урамы, 73
Тубылгы Тау авылы,423181

тел.: (8-84348) 3-82-58, факс: (8-84348) 3-82-44, Tub.Nsm@tatar.ru

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Яңа Чишмә авыл җирлеге Советы КАРАРЫ

КАРАР | КАРАР
19 март 2020 ел | № 64-147

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы “Тубылгы Тау авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын яисә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар, муниципаль вазыйфаларны яисә җирле администрация башлыгы вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү тәртибе хакында

"Коррупциягә каршы тору турында" 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы, "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы һәм "Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында" 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законнар, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Уставы, «Контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфаларын яисә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфаларын биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү тәртибе турында» 2017 елның 19 июлендәге 56-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына таянып, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы «Тубылгы Тау авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына нигезләнеп, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Тубылгы Тау авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Расларга:

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы “Тубылгы Тау авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын яисә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар, муниципаль вазыйфаларны яисә җирле администрация башлыгы вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү тәртибе турындагы Нигезләмәне расларга (1 нче икушымита);

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Тубылгы Тау авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларга билгеләнгән гражданнар тарафыннан үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында,

шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат һәм муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирергә тиешле муниципаль вазыйфалар Исемлеге (2 нче кушымта).

2. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Тубылгы Тау авыл җирлеге Советының 2016 елның 13 июнендәге 12-31 номерлы «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Тубылгы Тау авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүгә дәгъва кылучы гражданнарның керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук Яңа Чишмә муниципаль районы Тубылгы Тау авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның керемнәре, чыгымнары турында белешмәләр бирү турында " гы карары, үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны "Интернет" мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмати рәсми порталы"нда (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru .бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Тубылгы Тау авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Тубылгы Тау авыл җирлеге Башлыгы Ф.Ф.Исмагилов

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Тубылгы Тау авыл җирлеге Советының
2020 елның 19 мартындагы №64-147
карарына 1 нче номерлы кушымта

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы “Тубылгы Тау авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын яисә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар, муниципаль вазыйфаларны яисә җирле администрация башлыгы вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү тәртибе хакында
Нигезләмә

1. Әлеге Нигезләмәнең җайга салу предметы:

1.1. Әлеге Нигезләмә белән "Коррупциягә каршы тору турында" 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы, "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы һәм "Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында" 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә муниципаль вазыйфа яки контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүгә дәгъва итүче гражданнарның, контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфаларын яисә җирле администрация башлыгы вазыйфаларын биләүче затларның, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре (алга таба - керемнәр, чыгымнар, милек һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат)турында белешмәләр бирү тәртибе билгеләнә.

1.2. Әлеге Нигезләмә муниципаль сайлаулар нәтиҗәләре буенча гамәлгә ашырыла торган муниципаль вазыйфаларны биләүгә дәгъвачыларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирүгә бәйле мөнәсәбәтләргә кагылмый.

2. Керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат тапшыру тәртибе һәм сроклары:

2.1. Керемнәр, чыгымнар, милек һәм милек характерындагы йөкләмәләр турында мәгълүматлар федераль законнар нигезендә расланган тәртиптә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын яисә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар, контракт буенча муниципаль вазыйфаларны яисә җирле администрация башлыгы вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан белешмә формасында тапшырыла.

2.2. 2.1. пунктында каралган белешмә керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү өчен махсус мәгълүмат ресурсы аша (dohod.tatar.ru) тутырыла һәм Татарстан Республикасы Президентына тапшырыла. Күрсәтелгән белешмәнең күчермәсе муниципаль вазыйфаны яисә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар, контракт буенча муниципаль вазыйфаларны яисә җирле администрация башлыгы вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан имзаланган кәгазьдә, тиешле муниципаль районда (шәһәр округында) коррупцион һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи затка җибәрелә һәм законнар нигезендә сакланырга тиеш.

2.3. Әгәр федераль законда башкача билгеләнмәгән булса, муниципаль вазыйфаны яисә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүгә дәгъва кылучы граждан түбәндәге мүгълүматлар тапшыра:

1) муниципаль вазыйфаны, контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләү өчен документлар тапшыру елына кадәр булган календарь елы өчен барлык чыганаклардан (элеккеге эш урыны буенча яки сайланулы вазыйфа биләгән урын буенча керемнәр, пенсияләр, пособиеләр, башка түләүләр) барлык чыганаклардан алынган керемнәр турында белешмәләр, шулай ук граждан тарафыннан муниципаль вазыйфаны, контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләп тору өчен документлар тапшыру аеннан алдагы айның беренче числосына (хисап датасына) үзенә милек хокукы булган мөлкәт турында белешмәләр;

2) граждан тарафыннан муниципаль вазыйфа, контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләү өчен документлар тапшыру елына кадәрге календарь елы өчен хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының барлык чыганаклардан (хезмәт хакын, пенсияләрне, пособиеләрне, башка түләүләрне дә кертеп) алынган керемнәре турында белешмәләр, шулай ук граждан тарафыннан муниципаль вазыйфаны, контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләү өчен документлар тапшыру аеннан алдагы айның беренче числосына (хисап датасына) аларның милек хокукындагы мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр;

3) хисап чорында (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр) үзенең һәм хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының җир кишәрлеге, башка күчемсез милек, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр сатып алу (оешмаларның устав (җыю) капиталларында пайлар, катнашу өлеше) буенча чыгымнар турында мәгълүматлар, әгәр мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы әлеге гражданның һәм аның хатынының (иренең) хисап чорына кадәрге өч елгы гомуми кеременнән артса, һәр алыш-бирешләрнең гомуми суммасы һәм әлеге алыш-бирешләр кылган акчаларны алу чыганаклары турында турында белешмәләр.

2.4. Муниципаль вазыйфаны биләүче зат, авыл җирлекләренең вәкиллекле органнары депутатларының муниципаль вазыйфаларын биләүче һәм үз вәкаләтләрен даими булмаган нигездә гамәлгә ашыручы затлардан тыш, яисә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче зат ел саен, хисап чорыннан соң килүче елның 30 апреленнән дә соңга калмыйча түбәндәге мәгълүматлар тапшыра:

1) хисап чорында (1 гыйнвардан 31 декабргә кадәр) барлык чыганаклардан (акчалата бүләкләүне, пенсияләрне, пособиеләрне, башка түләүләрне дә кертеп) алынган керемнәр турында белешмәләр, шулай ук милек хокукындагы мөлкәт һәм милек характерындагы йөкләмәләре буенча хисап чоры ахырына булган мәгълүматлар турында белешмәләр (31 декабрь);

2) хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының хисап чорында барлык чыганаклардан (хезмәт хакын, пенсияләрне, пособиеләрне, башка түләүләрне дә кертеп) алынган керемнәре турында белешмәләр, шулай ук милек хокукындагы мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре буенча хисап чоры ахырына булган мәгълүматлар турында белешмәләр (31 декабрь);

3) хисап чорында (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр) үзенең һәм хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының җир кишәрлеге, башка күчемсез милек, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр сатып алу (оешмаларның устав (җыю) капиталларында пайлар, катнашу өлеше) буенча чыгымнар турында мәгълүматлар, әгәр мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы әлеге гражданның һәм аның хатынының (иренең) хисап чорына кадәрге өч елгы гомуми кеременнән артса, һәр алыш-бирешләрнең гомуми суммасы һәм әлеге алыш-бирешләр кылган акчаларны алу чыганаклары турында турында белешмәләр.

$2.4^{1}$. . Авыл җирлегенең вәкиллекле органы депутатының муниципаль вазыйфасын биләп торучы һәм үз вәкаләтләрен даими булмаган нигездә гамәлгә ашыручы зат депутат итеп сайланганнан соң, аңа вакантлы

депутат мандатын тапшыру яки аның вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыруы туктатылган көннән соң дүрт ай эчендә керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хисап чоры дәвамында «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килү-килмәвен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 1 өлешендә каралган алыш-бирешләр башкарылган очракта, мәгълүмат тапшыру елына кадәрге һәр ел өчен (хисап чоры) мәгълүмат бирә. Хисап чоры дәвамында мондый килешүләр башкарылмаса, әлеге зат бу хакта Татарстан Республикасы Президентына хәбәрнамәне әлеге Нигезләмәгә кушымта нигезендәге форма буенча 2.2 пунктында каралган махсус мәгълүмат ресурсыннан файдаланып җибәрү юлы белән хәбәр итә. Әлеге пунктта каралган хәбәрнамәләр, шулай ук (хисап чоры дәвамында «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 1 өлешендә каралган алыш-бирешләр башкарылган очракта) хисап чорыннан соң килүче елның 30 апреленнән дә соңга калмыйча бирелә.

Авыл җирлегенең вәкиллекле органы депутаты муниципаль вазыйфасын биләүче һәм үз вәкаләтләрен даими булмаган нигездә гамәлгә ашыручы зат тарафыннан имзаланган кәгазьдәге хәбәрнамәнең күчермәсе тиешле муниципаль районда (шәһәр округында) коррупцион һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи затка җибәрелә һәм законнар нигезендә сакланырга тиеш.

2.5. Әгәр әлеге Нигезләмә нигезендә үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр биргән гражданга муниципаль вазыйфа буенча вәкаләтләр бирелмәгән булса (күрсәтелгән муниципаль вазыйфага билгеләнмәгән, сайланмаган), контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасына билгеләнмәгән булса, бу белешмәләр аның язма гаризасы буенча кире кайтарыла.

3. Керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында төгәлләштерелгән мәгълүмат бирү.

3.1. Контракт буенча муниципаль вазыйфа яисә җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүгә дәгъва итүче граждан, контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын яисә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче зат, үзе тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, милек һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турындагы белешмәләрдә нинди дә булса мәгълүматлар чагылдырылмавын яисә тулысынча чагылдырылмавын ачыкласа, яки хаталар тапса, ул Татарстан Республикасы Президентына әлеге Нигезләмәдә каралган тәртиптә керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында төгәл мәгълүматлар (алга таба - төгәлләштерелгән белешмәләр) тапшырырга хокуклы.

3.2. Контракт буенча муниципаль вазыйфаны яисә җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүгә дәгъва итүче граждан күрсәтелгән белешмәләрне биргән көннән бер ай эчендә төгәлләштерелгән белешмәләрне тапшырырга хокуклы.

3.3. Контракт буенча муниципаль вазыйфа яисә җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче зат әлеге нигезләмәнең 2.4 һәм 2.41 пунктларында күрсәтелгән сроклар тәмамланганнан соң бер ай эчендә төгәлләштерелгән мәгълүматларны тапшырырга хокуклы.

Керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат тапшырмау яки белә торып дөрес булмаган яки тулы булмаган белешмәләр биргән өчен җаваплылык.

4.1. Муниципаль вазыйфаларны яисә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затлар керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар тапшырмау, шулай ук дөрес булмаган яки тулы булмаган белешмәләр бирүләре өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы булалар.

4.2. Муниципаль вазыйфаны яки контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затның керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматларны объектив сәбәпләр аркасында тапшыру мөмкинлеге булмау факты, яисә шул турыда гариза Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан билгеләнә торган тәртиптә каралырга тиеш.

4.3. Җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына, керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яки тулы булмаган мәгълүмат биргән депутатка, әлеге мәгълүматларны бозып күрсәткән очракта, бу мәгълүматларны бозып күрсәтү зур әһәмияткә ия булмаганда, түбәндәге җаваплылык чаралары кулланылырга мөмкин:

1) кисәтү;

2) депутатны, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасын муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органында, җирле үзидарәнең сайланулы органындагы вазыйфадан, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органында, җирле үзидарәнең сайланулы органында вазыйфа биләүдән мәхрүм итеп, аның вәкаләтләре вакыты беткәнче азат итү;

3) даими нигездә вәкаләтләрне гамәлгә ашырудан азат итү, даими нигездә вәкаләтләрен гамәлгә ашыру хокукыннан аның вәкаләтләре вакыты беткәнчегә кадәр мәхрүм итү;

4) муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органында, җирле үзидарәнең сайланулы органында вазыйфаларны биләүне аның вәкаләтләре срогы тәмамланганчы тыю;

5) даими нигездә вәкаләтләрен үтәүне вәкаләтләр срогы тәмамланганчы тыю.

4.4. Әлеге Нигезләмәнең 4.3 пунктында каралган җаваплылык чараларын куллану турында Татарстан Республикасы Президенты гаризасы (алга таба – җаваплылык чаралары) аларны куллану турында Карар кабул итәргә вәкаләтле җирле үзидарә органы тарафыннан әлеге органга гариза кергән көннән 30 көннән дә соңга калмыйча карала. Татарстан Республикасы Президенты гаризасын карау нәтиҗәләре буенча җаваплылык чарасын куллану яисә җаваплылык чарасын кулланудан баш тарту турында Карар кабул ителә.

Хисап чорында керемнәр, чыгымнар, милек һәм милек характерындагы йөкләмәләр турында дөрес булмаган яки тулы булмаган белешмәләр биргән өчен бары тик бер төрле генә җаваплылык чарасы кулланылырга мөмкин.

Җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты, керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яки тулы булмаган белешмәләр биргән депутатка, күрсәтелгән затка карата җаваплылык чараларын куллану турында карар кабул итәргә вәкаләтле орган тарафыннан аңа карата күрсәтелгән чараларны куллану турындагы мәсьәләне караганчыга кадәр биш эш көненнән дә ким булмаган вакыт эчендә җаваплылык чараларын куллану турындагы мәсьәләне карау турында язма рәвештә хәбәр ителә.

Җаваплылык чарасын куллану турындагы карарда коррупциячел хокук бозуга күрсәтмәдә депутат, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты тарафыннан бозылган норматив хокукый актлар нигезләмәләре, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә карарга карата шикаять бирү хокукы булырга тиеш.

Җаваплылык чарасын кулланудан баш тарту турындагы карарда мондый баш тартуның нигезле дәлиле булырга тиеш.

Җаваплылык чарасын куллану яисә җаваплылык чарасын кулланудан баш тарту турындагы карарның күчермәләре аны кабул иткән көннән биш эш көне эчендә депутатка, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына имзалатып тапшырыла яисә тапшыру турында хәбәрнамә белән почта аша җибәрелә, шулай ук Татарстан Республикасы Президентына җибәрелә.

Җаваплылык чарасын куллану яисә җаваплылык чарасын кулланудан баш тарту турындагы карарга карата Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә шикаять бирелергә мөмкин.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Яңа Чишмә авыл җирлеге Советының
2020 елның 19 мартындагы №64-147
карарына 2 нче номерлы кушымта

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Тубылгы Тау авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларга билгеләнгән гражданнар тарафыннан үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат һәм муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирергә тиешле муниципаль вазыйфалар Исемлеге

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Тубылгы Тау авыл җирлеге Башлыгы,

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Тубылгы Тау авыл җирлеге Советы депутатлары.

Муниципаль вазыйфаны яки контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар, муниципаль вазыйфаларны яисә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү тәртибе турындагы Нигезләмәгә кушымта

Татарстан Республикасы Президентына
________________________________

Хәбәрнамә

Мин, Яңа Чишмә муниципаль районы Тубылгы Тау авыл җирлеге депутаты ___ _______________________________________________________,
фамилиясе, исеме һәм (булса) атасының исеме

«___»________________ _______елда туган, паспорт сериясе ______________________ №_______________,
____________________________________________________________
тапшыру датасы һәм паспорт биргән орган
_______________________________________________________________________________,
«Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 121 статьясындагы 42 өлеше һәм «Муниципаль вазифага яисә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасына дәгъвалаучы гражданнарның, муниципаль вазифаларны яисә җирле администрация башлыгы вазыйфаларын биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү тәртибе турында» 2017 елның 19 июлендәге 56-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы $4^1$ өлеше нигезендә хәбәр итәм: минем, хатыным (ирем) һәм (яки) балигъ булмаган балаларым тарафыннан хисап чоры дәвамында 1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр № 230-ФЗ «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен контрольдә тоту турында»гы Федераль законда каралган сатып алу буенча алыш-бирешләр (җир кишәрлеге, башка күчемсез милек объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр, акцияләр сатып алу (оешмаларның устав (җыелма) капиталларында катнашу өлеше, пайлары), аларның гомуми суммасы тормыш иптәшем (хатыным) белән бергә хисап чорына кадәрге өч елгы безнең гомуми керемебездән артып киткән сатып алу буенча алыш-бирешләр башкарылмады.

Әлеге белешмәләрнең дөреслеген раслыйм.

«____»_____________ 20__ ел ________________________________
гариза биргән затның имзасы

_______________________________________________________________________________
(хәбәрнамәне кабул итүгә вәкаләтле затның фамилиясе, исеме һәм отчествосы(булса) һәм имзасы)"